# КАРАР

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге составына керүче Иске Ибрай авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2019 елның 28 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә "2020 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Иске Ибрай авылы территориясендә теркәлгән кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә (1 төркем инвалид, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән алдагы эшләрне башкару буенча:

1) Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:

- Кызыл Армия , Тукай, 1 нче Май, Үзәк, Җиңү, Бабил, Кызыл Чишмә, Яшьләр урамнарына грунт белән нигез салу.
- Иске Ибрай авылы юлларына вак таш сатып алу һәм түшәү.
- кышкы юлларны карап тоту.

2) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- Су суырткыч һәм скважина өчен комплектлаштыру җиһазлары сатып алу

3) Авыл территориясен төзекләндерү тәртибен раслау, аны конторольдә тоту, авыл территориясендә төзекләндерү тәртибенә нигезләнеп оештыру

- урамнарны яктыртуны оештыру буенча электр яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру

ӘЙЕ ЮК ТЫЕЛЫП КАЛАМ

" белән килешәсезме?" мәсьәләсе буенча 2019 елның 28 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1321 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 708 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
- "әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 706 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
- «тыелып калам» позициясе өчен җыенда катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай авыл җирлеге составына керүче Иске Ибрай авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын мәгънәсендә.
2. "Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегенең Иске Ибрай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм студентлардан тыш, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә юнәлдерүгә килешәсезме?":
1) Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:
- Кызыл Армия , Тукай, 1 нче Май, Үзәк, Җинү, Бабил, Кызыл Чишмә, Яшьләр урамнарына грунт белән нигез салу.
- Иске Ибрай авылы юлларына вак таш сатып алу һәм түшәү.
- кышкы юлларны карап тоту.
2) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- Су суырткыч һәм скважина өчен комплектлаштыру җиһазлары сатып алу
3) Авыл территориясен төзекләндерү тәртибен раслау, аны конторольдә тоту, авыл территориясендә төзекләндерү тәртибенә нигезләнеп оештыру
- урамнарны яктыртуны оештыру буенча электр яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру

3. Әлеге карарны Иске Ибрай авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.
4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы М.Г.Минигулов